ОАК БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН АВИАТӨЗЕЛЕШ КОРПОРАЦИЯСЕ

ТУПОЛЕВ ГАВАМИ АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

**"ТУПОЛЕВ" ГАҖ ФИЛИАЛЫ –**
**С.П.ГОРБУНОВ ИС. КАЗАН АВИАЦИЯ ЗАВОДЫ**

# ЫШАНЫЧЛЫ РОССИЯ

## Тарих


**Россиянең ышанычлы канатлары!**

**С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводы 1927 елда төзелә һәм һәрвакыт хәрби һәм пассажир самолетларының яңа типларына нигез салуда алдынгы булып килә. Гамәлдә булган елларда Казан авиация заводы гомуми 20 мең берәмлек күләмендә 22 типта һәм модификациядә авиация техникасы чыгарды. Берләшмәдә төрле чорларда Пе-2, Пе-8, Ту-4, Ту-16, Ту-104, Ил-62М, Ту-22, Ту-22М3 кебек атаклы очкычлар җитештерелде.**

**С.П.Горбунов ис. КАЗ – "Туполев" ГАҖ филиалы – югары интеллектуаль һәм техник потенциалы булган заманча предприятие, хәрби һәм граждани самолетлар җитештерүдә 87 еллык эш тәҗрибәсенә ия, Россия Федерациясендәге иң эре авиатөлезеш комплексларының берсе булып тора.**

**2008 елда С.П.Горбунов ис. КАЗ акционерлашты. Акцияләрнең 100%лы хуҗасы – "Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе" ГАҖ.**

**2014 елдан башлап предприятие "Туполев" ГАҖ филиалы булды.**




**Казан авиация заводының завод белән идарә итү бинасы**

## Уртача магистарль пассажирлар самолеты Ту-214





### Ту-214 очкычының төп сыйфатламалары:

| | |
|---|---|
| Җирдән күтәрелү массасы, макс, тонна | 110.75 |
| •Әзерләнгән самолет массасы, тонна ± 1.5% | 61.6 |
| •Коммерция авырлыгы, макс, тонна | 25.20 |
| •Пассажирлар саны, макс | 210 |
| •Очыш ераклыгы, чакрым | 7 200 |
| •Крейсер тизлеге, чм/сәг | 850 |
| •Уртача ягулык сарыфы, кг/сәг | 3500 |
| •Тулай ягулык сарыфы, г/кгс.сәг | 595 |
| •Ягулык нәтиҗәсе, г/пасс·чм | 19,3 |

# Продукция

## Махсус авиация

**Ту-214 самолеты эксплуатациядә үзен яхшы яктан күрсәтеп, махсус билгеләнештәге тулы бер самолетлар рәтен ясауда база сыйфатында сайланды.**



**Ту-214 ОН – махсус билгеләнешле самолет, ачык һаваны күзәтүнең авиация системасы белән тәэмин ителгән**




**Ту-214 ПУ – идарә пунктлары урнаштырылган, махсус билгеләнештәге самолет**




**Ту-214 СР – ретрансляторлы, махсус билгеләнешле самолет**

**Ту-214СУС – махсус билгеләнештәге самолет, очыш маршрутында дөньяның теләсә кайсы ноктасында элемтәгә керү мөмкинлеген бирә торган элемтә төене һәм махсус техник чаралар белән җиһазландырылган.**

# Продукция

## Стратегик авиация

### Стратегик бомбага тотучылар
### Ту – 160

- Модернизацияләү
- Капиталь ремонт
- Тикшерүдә тоту-яңарту хезмәтләрен күрсәтә



Ту-160 самолетының күтәрелүе



Ту-160 самолеты очыш вакытында



Ту-160 күктә ягулык белән тәэмин итә

## Стратегик бомбага тотучылар
## Ту – 22М3

- ремонтлау
- модернизацияләү



Ту-22М3 очу-сынау станциясендә



Ту-22М3 самолеты очыш вакытында



Ту-22М3 самолетының күтәрелүе

# Кадрлар белән эшләү

**Укыту-җитештерү үзәгендә өйрәнү-эш остаханәләре урын алган. Бу бинада ел саен 2800 артык эшче һәм 450 инженер-техник хезмәткәр һөнәр ала һәм үзенең квалификациясен күтәрә.**





## Инновацияләр

- Нәтиҗәле технологияләр куллана
- Чыгымнарны минимальләштерә
- Җайланмадан файдалануны оптимальләштерә
- Җыю методларын рациональләштерә
- Эксплуатациядә ышанычлы һәм җайлы
















БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН
АВИАТӨЗЕЛЕШ
КОРПОРАЦИЯСЕ

ТУПОЛЕВ
ГАВАМИ
АКЦИОНЕРЛЫК
ҖӘМГЫЯТЕ

"ТУПОЛЕВ" ГАҖ ФИЛИАЛЫ –
С.П.ГОРБУНОВ ИС. КАЗАН АВИАЦИЯ ЗАВОДЫ

# ИГЪТИБАР ӨЧЕН РӘХМӘТ!

www.tupolev.ru